**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР
_____

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ______

Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24, 28 ст., 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, район Уставы, Актаныш районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләренең Генераль планнарын эшләү турында» 2021 елның 23 апрелендәге ПР-73 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

2.1. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында, Күҗәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

2.2. «Актаныш таңнары» газетасында ачык тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны бастырырга.

3. Ачык тыңлауларны үткәрү срогын 1 көндә билгеләргә.

- ачык тыңлаулар уздыру вакыты - 2022 елның 19 апреле:
- Үткәрү урыны: 10.00 сәгатьтә - Совет ур., 23 нче йорт, Иске Урьяды авыл клубында;
- Үткәрү урыны: 12.00 сәгатьтә - Адай авылы, Горький ур., 2 нче йорт, «Адай мәдәният йорты» МБУ;
- Үткәрү урыны: 14.00 сәгатьтә - Кужәкә авылы, Совет ур., 28 йортта;

4. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге башлыгы А.К.Галиәхмәтовны ачык тыңлаулар уздыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

5. Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен, кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Э.Н.Фәттахов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
__ _______ 2022 ел, №___
кушымта

Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

Әлеге тәртип Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатыннан эшләнгән һәм авыл җирлеге гражданнарының генераль план проекты буенча фикер алышуда катнашу тәртибен, шулай ук генераль план проекты буенча халык фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Генераль план проекты буенча гражданнарның фикер алышуда, ачык тыңлауларда катнашуы, авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан генераль план проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне Актаныш районы Башкарма комитетына җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Җирлекнең генераль планы проектының график һәм текст материаллары экспозициясе Күҗәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

3. Җирлекнең генераль планы проекты материаллары белән танышу вакыты: дш-җм 9.00 сәгатьтән 16:00 гә кадәр, (төшке аш 12.00 дән 13.00 гә кадәр).

4. Генераль план проекты территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында fgis.economy.gov.ru басылып чыгарга тиеш.

5. Җирлекнең генераль планы проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү түбәндәге адрес буенча гамәлгә ашырыла: 423740, ТР, Актнаыш авылы, Ленин проспекты, 17 йорт, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, инфраструктур үсеш бүлеге;

6. Ачык тыңлаулар әзерләү һәм уздыру, шулай ук генераль план проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алуны ачык тыңлаулар уздыру өчен җаваплы тарафыннан башкарыла.

7. Генераль план проекты буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны, документлар белән тәэмин итүне ачык тыңлаулар секретаре гамәлгә ашыра.

8. Ачык тыңлаулар башланганчы, секретарь тарафыннан ачык тыңлауларда катнашучыларны теркәү башкарыла. Теркәлү битендә ачык тыңлауларда катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны адресы күрсәтелә.

9. Ачык тыңлаулар уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
- докладчыга төп доклад өчен 20 минуттан да артык түгел;
- җирлекнең генераль планы проекты турында фикер алышу буенча чыгышлар өчен 3 минуттан артык түгел;
- репликалар һәм кисәтүләр өчен - 2 минуттан артык түгел.

10. Ачык тыңлаулар уздырганда секретарь тарафыннан генплан проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә ачык тыңлауларны оештыручы һәм секретаре кул куя.

11. Ачык тыңлауларны оештыручы ачык тыңлаулар уздырылган көннән 2 көн эчендә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә күрсәтелә:

- ачык тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең исеме;
- ачык тыңлаулар уздыру датасы, вакыты һәм урыны;
- ачык тыңлауларда катнашкан авыл җирлеге гражданнары саны;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар.

12. Бәяләмәгә ачык тыңлауларны оештыручы имза сала һәм ачык тыңлаулар беркетмәсе белән бергә «Актаныш таңнары» газетасында, районның рәсми сайтында, Күҗәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында мәҗбүри бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.